**ГЛАВА**
**БОЛЬШЕЕЛГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422640, с. Большая Елга,
ул.Октябрьская, дом 25

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ОЛЫ ЕЛГА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422640, Олы Елга,
Октябрь урамы, 25 йорт

Тел.: (84361) 25-264, факс: (84361) 25-265, эл.адрес: Belg.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 ноябрь, 2021 ел Олы Елга ав. № 2

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга һәм Сорочьи Горы авыл торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга авыл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2021 елның 26 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга авыл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2021 елның 26 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга авыл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын 2021 елның 29 ноябрендә 9 сәгать 00 минутка билгеләргә.
4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга авыл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе

буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын 2021 елның 29 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга авыл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының бишенче этабын 2021 елның 29 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

6. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга авыл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының алтынчы этабын 2021 елның 30 ноябрендә 9 сәгать 00 минутка билгеләргә.

7. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга авыл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының җиденче этабын 2021 елның 30 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.

8. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга авыл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 30 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

9. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта көн итүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

10. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга, Казаклар, Сорочьи Горы, Кама поселогы авыл торак пунктлары территорияләрендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге бүлектә торып укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан гайре, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга Сез ризамы?

– Олы Елга, Сорочьи Горы авылларындагы суэтем скважиналары өчен тирәнлек насослары сатып алу, урнаштыру һәм алыштыруга (шартнамә буенча эшкә түләүгә);

– авыл җирлеге торак пунктларындагы урам утларына энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру һәм алыштыруга (шартнамә буенча эшкә түләүгә);

– Сорочьи Горы авылында Садовая-2 урамында юлларны ремонтлауга (вак таш сатып алуга, аны ташу буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә, вак ташны җәюгә, эш өчен түләүгә);

– Олы Елга авыл җирлеге торак пунктларында урамнарның юл өлешен кышын карап тотуга (кардан чистартуга) (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә);

– Олы Елга авылында Нариманов урамындагы Бизнә инеше аша салынган җәяүлеләр күперен ремонтлауга (материал сатып алуга, шартнамә буенча эш өчен түләүгә);

– Олы Елга авылы зиратына илтүче күперне ремонтлауга (материал сатып алуга, шартнамә буенча эш өчен түләүгә);

– Олы Елга авылындагы Новая-1 урамында тышкы суүткәргеч салуга (220 см тирәнлектә траншея казуга, 63 мм диаметрлы торбаларны сузуга, задвижка, ЖБИ боҗрасы сатып алу һәм урнаштыру, траншеяны күмүгә);

– Казаклар авылында балалар мәйданчыгы төзү (инвентарь сатып алу, урнаштыру, шартнамә нигезендә эш хакы түләү);

– Олы Елга авылында обелискны ремонтлау (материал сатып алу, эшләтү, шартнамә нигезендә эш хакы түләү);

"ЯКЛАП" "КАРШЫ".

11. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге башлыгының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга һәм Сорочьи Горы авыл торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында" 2021 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы карарын 2021 елның 15 ноябреннән үз көчен югалткан дип танырга.

12. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 йорт; Сорочьи Горы авылы, Үзәк урам,16а йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

13. Карар игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге башлыгы Ф.А.Садриев